РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2025 елның 10 феврале** **Чистай шәһәре** **№39/2**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 14.02.2014 ел, №28/6 карары белән (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 21.05.2015 №40/2; 23.12.2015 №3/7; 15.12.2016 №10/6; 31.08.2017 №17/7; 21.03.2018 №23/2; 24.10.2018 28/6; 04.07.2019 №36/1; 13.05.2020 №46/6; 28.04.2021 №7/5; 12.05.2022 №14/3; 24.05.2023 №22/4; 30.05.2024 №30/5 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) кабул ителгән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 5 статьяның 1 пунктында:
27 пунктчада «җирлек территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;
түбәндәге эчтәлекле 43 пунктча өстәргә:
«43) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру»;
1.2. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7 статья. Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы.

Җирлектә муниципальара хезмәттәшлек федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла»;
1.3. 33 статьяның 1 пунктындагы 16 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;
1.4. 40 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:
«13) аның чит ил агенты статусын алуы»;
1.5. 49 статьяда:
1.5.1. 1 пунктның 3 пунктчасындагы тугызынчы абзацында «җирлек территориясендәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны үстерүне һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;
1.5.2. 3 пунктта 1-5 пунктчаларны түбәндәге эчтәлекле 1-3 пунктчаларга алмаштырырга:
«1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;
2) җирлек территориясендә муниципаль контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;
3) әлеге Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә бүтән вәкаләтләр»;
соңгы абзацта «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон статьясындагы сылтаманы «Россия Федерациясендә муниципаль контрольнең дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга сылтама белән алмаштырырга;
1.6. 80 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасының яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасының электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында теркәлгән карарны ул Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән кергән көннән алып җиде көн эчендә «Чистай хәбәрләре» газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Чистай муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы рәсми сайтында (www.chistopol.tatar.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов